١٢٤نچی صان.

بهاسی ١۵ تین.

١٠٢نچی یل.

چقدی ١٢ نچی آپریل ٢٠١٣نچی یل

# آڭ

یازلو حقی

ژورنالنی ایلتوب طابشرو ایله:

بر یلغه .......٣ صوم — تین.

یارطی یلغه .......... ١ " ٧۵ "

اوچ آیغه ............. ١ " — "

آدریس آلماشدرو اوچون ٢٠

چیت مملکت اوچون:

بر یلغه................. ۵ صوم.

یارطی یلغه ........... ٣ صوم.

**Такса объявлений въ журналѣ «АНГЪ»:**

На обложкѣ, 2-я стран. на 1 разъ за строку петита 40 коп., 3-я и 4-я страницы 20 коп., (в страницѣ 2 столбца).

اداره خانه‌سی

قزانده ، مه‌سکه‌وسکی اورامده.

یبه‌رلگان یازمه‌لرنی ایه‌لری "گانارارلی" یایسه "گانارارسز" دیب بیلگوله‌ب یبه‌رسونلر. گانارارى بیلگوله‌نمه‌گان ماتیریاللر حقسز حساب ایتلوب ، یاراقلیلری "آڭ"ده باصلورلر ، یاراقسزلری مارکه‌لری بولسه کیری یبه‌رلور ، مارکه‌سزلری طاشلانورلر. یازمه‌لر قارا ایله هم امضالر تفصیلا یازلورغه تییش. امضاسز یازمه‌لر درج ایتلمه‌س ، یازمه‌لرنڭ املا و اسلوبني توزه‌تورگه اداره احتیارلیدر.

مراجعت اوچون آدریس:

**Казань, контора журнала «АНГЪ».**



عبدالله توقایف

Габдулла Тукай (1886-1913)

# Габдулла Тукаев үлде...

2нче апрель сишәмбе көн кич 8:15 сәгатьтә шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев Казанда Клячкин шифаханәсендә вафат итте.

«Аң» үзенең укучыларын зур милли югалту белән бүлешергә сүз табудан гаҗиз. Тукаевның вафаты белән Төньяк-төрек әдәбияты үзенең иң сөелеп укыла торган шагыйрьләреннән мәхрүм калды. Әдәбиятыбызның талантларга иң мохтаҗ заманында ачылып, югары ноктага ирешеп җитмәстән зур бер милли талантның җуелуын бөтен милләт зур хәсрәт белән генә каршы ала аладыр.

Милләтнең бу әдәби югалтуы «Аң» өчен хосусый сурәттә бер югалудыр: Габдулла Тукаев аның исем бирүчесе, оештыручылардан берсе, һәм аның даими мөхәррирләреннән берсе иде. Ул вафатыннан ике генә сәгать элек, бу сан «Аң»ны актык мәртәбә бизәгән шигырьләренең карикатурасын сорап язды; ләкин тәкъдир аңар бу шигырьләрен басылган хәлдә күзеннән кичерергә мөмкинчелек бирмәде...

Габдулла Тукаев үлде, ләкин аның исеме, аның шигырьләре милләт йөрәгендә тиз үлмәс. Алар, бәрәкәтле орлыклар шикелле, милләт рухында милли аң үстерерләр, халкыбызга, телебезгә, гадәтләребезгә мәхәббәт тудырып торырлар.

Җир йөзен тарсынган рухың Ходаның галәмендә булсын газиз шагыйрь! («Аң» журналы, 1913 елның 10нчы апреле).



# عبدالله توقايف ئولدى...

٢نچى آپريل سهشمبه كون كيچ ٨:١٥ ساعتده شاعر عبدالله افندى توقايف قزانده كلهچكين شفاخانهسنده وفات ايتدى.

”آڭ“ اوزينڭ اوقوچيلرينى زور ملى ضياع بلهن تعزيه ايتهرگه سوز طابودن عاجز. توقايفنڭ وفاتى بلهن شمال تورک ادبياتى اوزينڭ ايڭ سويلوب اوقولا طورغان شاعرندن محروم قالدى. ادبياتمزنڭ طالانتلرغه ايڭ محتاج زماننده استعداد فوق العادهسى آچلوب، كمالينه ايرشوب يتمهسدن زور بر ملى طالانتنڭ جويالووينى بتون ملت زور حسرت بلهن گنه قارشى آلا آلادر.

ملتنڭ بو ادبى ضياعسى ”آڭ“ اوچون خصوصى صورهتده بر ضياعدر: عبدالله توقايف ”آڭ“نڭ اسم بيروچيسى، مؤسسلرندن برسى، هم آنڭ دائمى محررلرندن برسى ايدى. اول وفاتندن ايكى گنه ساعت ئلك، بو صان ”آڭ“نى آقتق مرتبه بيزهگان شعرلرينڭ كارريكتوراسينى صوراب ياتدى؛ لكن تقدير آڭار بو شعرلرينى مطبوع حالده كوزندن كيچرورگه مهلت بيرمهدى...

عبدالله توقايف ئولدى، لكن آنڭ اسمى، آنڭ شعرلرى ملت يورهگنده تيز ئولمهس. آنلر، بركة لى اورلقلر شيكللى، ملت روحنده ملى آڭ اوسدرورلر، خلقمزغه، تلمزگه، عادتلرمزگه محبت طودروب طورورلر.

يير يوزينى طارسنغان بلدن روحڭ خدانڭ بلدن عالمنده بولسون عزيز شاعر!

# Печән базары нинди булган?!

Бер заман бардым Печән базарына, —
Шунда мин таптым азык язарыма.

Иртә берлән кайнамакта бу базар,
Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр.

Кайсысы сатмактадыр, кайсы ала,
Берсе алдый, шунда берсе алдана.

Йөгрешәләр сөртенә дә абына
Барча мөэминнәр «Көфер почмагы»на.

*(Габдулла Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасыннан өзек)*

**Печән базары** XVIII гасырдан алып 1930 елларга кадәр Казанның Иске Татар бистәсендә эшләп килә һәм шәһәребезнең сәүдә, җәмгыять һәм мәдәният үзәге булып тора. Базарның бер урамы хәзерге Болак буеннан, ягъни Казан федераль университетының яныннан алып, Тукай урамының трамвай юлларына кадәр, икенчесе исә Татарстан урамыннан алып, Колхоз базары территориясенә кадәр урнаша. «Печән базары» дигән исем базарда печән сатканнан түгел, ә Сенная урамында урнашу сәбәпле барлыкка килә. Ә менә Колхоз базарыннан соң икенче бер базар китә. Анда инде мал-туары да, печәне дә, утыны да сатыла.

Базарның үзәге булып «**Печән базары мәчете**» тора. Ул 1845-1849 елларда ук төзелә. Бүгенге көндә бу мәчет «Нурулла мәчете» дип атала. «Көфер почмагы» — шул мәчеттән чыккач та булган почмак. Элегрәк, татар матбугаты барлыкка килгәнче, кешеләр шунда яңалыклар белән алмаша, искерәк карашлы мөселманнар җәдитчеләрне көферлектә гаепли.

Печән базарының буеннан буена кунакханәләр, сәүдә кибетләре һәм амбарлар, товар җитештерү биналары, чәйханәләр урнаша. Әмма бу базар сәүдә мәйданы гына булып калмыйча, татарларның җәмәгать үзәге дә булып тора. Кунакханәләрдә исә татар мәдәниятының атаклы шәхесләре яши бирә: шагыйрьләр, драматурглар, язучылар, актерлар. Бу тормышта төрле милләт вәкилләре кайнаганлыктан, теләсә нинди диярлек телне дә өйрәнеп була. Шунысы кызык: руслар әлеге базарга керергә курка, алар Болакның икенче ягында тормыш алып бара.

Базарның бетмәс-төкәнмәс кибетләрендә һәм ачык һавада урнашкан озын ләүкәләрдә төрле әйберләр саталар: милли киемнәр, калфак-түбәтәйләр, аяк киемнәре, комганнар, бизәкле намазлыклар, җылы шәлләр, Коръән китаплары... Күрше ләүкәләрдә исә Урта Азиядән кайткан ашамлыклар, тәм-том әйберләре, киптерелгән җиләк-җимеш. Кыскасы, барысы да бик яхшы сатыла һәм даими рәвештә табыш китереп тора, хуҗаларның мал-мөлкәте һәм байлыгы арткан арта бара, чөнки халык иртә таңнан алып кичке караңгылык төшкәнче шушы базарда йөри бирә.

Печән базары 1932 елдан бирле инде эшләми. Кызганыч ки, базарның күп кенә тарихи ядкарьләрен җимереп, алар урынына яңа биналар төзиләр.















# ИНТЕРЕСНЫЕ ФАКТЫ






Имя Габдуллы Тукая известно не только в Татарстане, но и далеко за её пределами. Его знают все, кто ценит искусство, кто любит поэзию. Творчество Тукая многогранно: он поэт и публицист, литературный критик и общественный деятель. Для развития татарской поэзии и в целом культуры он сделал также много, как Александр Пушкин для русской поэзии и культуры.

Габдулла Тукай хорошо знал русскую классику, много сил отдал переводам русской литературы на татарский язык. В своих переводах он донес до читателя мятежные стихи М.Ю.Лермонтова, поэзию А.Н.Майкова, И.С.Никитина, великие творения Л.Н.Толстого. Художественным авторитетом для него был А.С.Пушкин.

Осенью 1911 года началась переписка между Казанским комитетом по делам печати, то есть цензурой, жандармским управлением, губернаторской канцелярией, Казанской судебной палатой и Главным управлением по делам печати по поводу книги «Стихи Габдуллы Тукаева». Комитет, изучив книжечку, отдал многие стихотворения для перевода и высказал убеждение в необходимости наложить на нее арест и привлечь автора к суду.

На похороны Габдуллы Тукая пришло около десяти тысяч человек. 4 апреля 1913 года почти все татарские газеты посвятили ему специальные номера, в знак траура был отменен рабочий день в издательствах и книжных магазинах, занятия во всех медресе. Целую неделю в газетах продолжалась публикация телеграмм соболезнования из самых разных уголков России.

Сказка-поэма Тукая «Шурале» связана с деревней Кырлай. Именно здесь Тукай впервые услышал эту легенду. Один из современников Тукая рассказывает: «Габдулла любил щекотать других, как Шурале. Неподалеку от нас стояла бедная деревенька Новый Менгер. Говаривали, что жители этой деревни забили насмерть Шурале, потому, мол, они и такие бедные. Очевидно, Габдулла слышал об этом».

В честь Габдуллы Тукая назван ряд площадей и улиц в Татарстане, Башкортостане, Челябинской области, Казахстане, Узбекистане, а также улица в Анкаре и парк в Стамбуле (Турция).

Памятники Габдулле Тукаю установлены в Димитровграде (Ульяновская область), Москве, Санкт-Петербурге, в Казахстане и в Турции.

В странах-участницах Международной организации тюркской культуры 2011 год был объявлен «Годом Тукая».

Творчество Габдуллы Тукая преподается на уроках классической литературы в Синьцзян-Уйгурском автономном районе Китайской народной республики.

Имя Габдуллы Тукая присвоено Татарской государственной филармонии в Казани.

Государственная премия в области искусства Татарстана носит имя Габдуллы Тукая.

Песня «Туган тел», написанная на одноименное стихотворение Габдуллы Тукая, считается неофициальным гимном татар всего мира. Текст песни знает практически каждый представитель татарской нации.

В день рождения поэта, 26 апреля, на улице Баумана каждый год проводится акция «Мин татарча сөйләшәм».